**Республика Татарстан**
**Совет Верхне-Чершилинского сельского поселения**
**Сармановского муниципального района**

**Татарстан Республикасы**
**Сарман муниципаль районының Югары Чыршылы авыл җирлеге Советы**

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

24.06.2024 г. № 7

Җирле салымнар суммалары өлешендә
бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның
өстәмә нигезләрен билгеләү турында

«Төбәк салымнары суммалары өлешендә бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында» 2024 елның 12 апрелендәге 18-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, Сарман муниципаль районының «Югары Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына ярашлы рәвештә, Сарман муниципаль районының Югары Чыршылы авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Җирле салымнар суммалары буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләргә:

- варислар мирас хокукыннан баш тарткан, варислар булмаган яки мирас ачылганнан соң бер ел эчендә мирасны кабул итмәгән очракта үлгән яки үлгән дип игълан ителгән физик затларда бурычлар булу;

- Россия Федерациясе Салым кодексының 48 статьясында билгеләнгән сроклар тәмамланганнан соң физик затларда 500 сумнан артмаган суммада бурыч булу.

Төбәк салымнары суммалары буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләре булуын раслаучы документлар булып:

1) әлеге карарның 1 пунктының 1 пунктчасында күрсәтелгән нигез булганда:

а) физик затның яшәү урыны буенча салым органының бурыч суммасы турында белешмәсе;

б) үлем белән бәйле рәвештә салым органнарында физик затны исәптән төшерү турында мәгълүмат;

в) мирас хокукы турында таныклык бирү турында мәгълүмат булмау турында салым органы белешмәсе;

2) әлеге карарның 1 пунктындагы 2 пунктчасында күрсәтелгән нигез булганда, салым органының 500 сумнан артмаган бурыч булу турында белешмәсе.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга, шулай ук Сарман муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Югары Чыршылы авылы
Советы рәисе

И.Н. Камалетдинов